КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 апрель г.Казань № 286

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 67 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 67 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 октябрь, 716 нчы, 2017 ел, 15 февраль, 84 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Министрлык финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча эшчәнлекне тормышка ашырганда түбәндәгеләрне башкара:

а) Россия Федерациясе Бюджет кодексының $269^2$ статьясындагы 1 пунктында һәм Контракт системасы турында федераль законның 99 статьясындагы 8 өлешендә билгеләнгән эчке дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләре;

б) законнарда каралган очракларда җирле бюджетларның үтәлешен контрольдә тоту;

в) тикшерүләр, ревизия һәм тикшеренүләр үткәрү өчен кирәкле экспертизаларны билгеләү (оештыру);

г) мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан даими файдалану мөмкинлеген алу.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Контроль объектлары булып тора:

а) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр, алучылар), Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);

б) Россия Федерациясе Бюджет кодексының $266^1$ статьясындагы 2.1 пунктының җиденче һәм сигезенче абзацларында күрсәтелгән бюджет акчаларының баш администраторлары (администраторлары), финанс органнары, юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр;

в) гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре;

г) устав (тупланма) капиталларында Татарстан Республикасы катнашында хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең өлеше (кертеме) булган коммерция оешмалары;

д) юридик затлар (дәүләт учреждениеләре, дәүләт унитар предприятиеләре, дәүләт корпорацияләре (компанияләре), гавами-хокукый компанияләр, устав (тупланма) капиталларында гавами-хокукый компанияләр катнашкан хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең өлеше (кертеме) булган коммерция оешмалары, шәхси эшмәкәрләр һәм бәндәгеләр булган физик затлар:

Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) һәм (яки) дәүләт контрактлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы, шулай ук дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар алучы юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр;

Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар бирү турындагы шартнамәләрне (килешүләрне) һәм Министрлыкта шәхси счетлары ачылган (яки) дәүләт контрактларын үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча башкаручылар (тәэмин итүчеләр, подрядчылар);

е) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды белән идарә итү органнары;

ж) мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итү турындагы шартнамәләр буенча Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан акча алучы юридик затлар;

з) бюджет акчалары белән аерым операцияләрне гамәлгә ашыручы кредит оешмалары, алар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү өлешендә;

и) Контракт системасы турында федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен гамәлләре товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга юнәлдерелгән заказчылар, контракт хезмәтләре, контракт идарәчеләре, сатып алуларны гамәлгә ашыру комиссияләре һәм аларның әгъзалары, вәкаләтле органнар, вәкаләтле учреждениеләр, махсуслаштырылган оешмалар.»;

8 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктның «г» һәм «д» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда күрсәтмәләр һәм (яисә) боерыклар җибәрергә;

д) Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнамәләр җибәрергә;»;

23 пунктта:

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«в» пунктчасында «(күрсәтелгән чор 3 елдан артып киткән очракта, әлеге критерий иң югары приоритетка ия)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«г» пунктчасында «сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системалары» сүзләренә алмаштырырга;

37 пунктта «(бухгалтерия)» сүзен «хисаплылык, бухгалтерия (финанс)» сүзләренә алмаштырырга, «Министрлык тарафыннан кулланыла торган мәгълүмат системалары» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системалары» сүзләренә алмаштырырга;

45 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) контроль объектына күрсәтмә һәм (яки) боерык җибәрү хакында яки җибәрү өчен нигезләр булмау турында;»;

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

46 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«46. Күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү тикшерү объектына карата, контроль объектының урнашу урыны һәм күчмә тикшерү актын рәсмиләштерү урыны буенча тиешле контроль гамәлләрне гамәлгә ашырудан тора, алар барышында шулай ук кылган операцияләрнең бюджет хисаплылыгы, бухгалтер (финанс) хисаплылыгы һәм беренчел документларның факттагы туры килү-килмәве билгеләнә.»;

54 пунктның «б» пунктчасында «(бюджет)» сүзен төшереп калдырырга;

63 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) контроль объектына күрсәтмә һәм (яки) боерык җибәрү хакында яки җибәрү өчен нигезләр булмау турында;»;

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

64 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«64. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы «а» пунктчасында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, Министрлык Россия Федерациясе бюджет законнары һәм дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында тәкъдимнәр, күрсәтмәләр һәм хәбәрнамәләр җибәрә.»;

65, 66 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

67 пунктта «30» саннарын «10»саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин